**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.07.2023

г. Казань

**№** 95од

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2020 елның 26 декабрендәге 157од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә (2022 елның 3 июндәге 106од, 2023 елның 17 февралендәге 21од, 2023 елның 5 маендагы 62од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министр карары буенча граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентларында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына мөнәсәбәттә конкрет белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең зур төркемнәренә), шулай ук яңадан һөнәри әзерлекнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә квалификация таләпләре билгеләнергә мөмкин.»;

4.3 пунктта «, аларның квалификация таләпләренә туры килүләрен» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.12. Конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен алар тәкъдим иткән белем һәм (яки) квалификация турындагы документлар (гыйльми дәрәҗә бирү, гыйльми исем бирү (булган очракта), гражданлык яки башка төр дәүләт хезмәте үтү, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә

ашыру турындагы документлар нигезендә, шулай ук һөнәри дәрәҗәне бәяләүнең федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килмәгән ысулларын кулланып конкурс процедуралары нигезендә, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын исәпкә алып, шул исәптән индивидуаль әңгәмә, анкета, төркемле дискуссияләр үткәрү, реферат язу яки кандидатлар дәгъва итә торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча вазифа бурычларын үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча тест узуны кертеп, бәяли. Конкурс үткәрелә торган вазифалар төркеменә һәм категориясенә карап, төрле ысуллар кулланылырга мөмкин. Шул ук вакытта тест һәм кандидат белән индивидуаль әңгәмә барлык кандидатлар өчен мәҗбүри ысуллар булып тора.

Конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри дәрәҗәләрен чагыштыруны, аларның һөнәри белем дәрәҗәләрен, гражданлык хезмәте стажын яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эшен, шулай ук аларның белгечлекләре, әзерлек юнәлешләре (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең зур төркемнәрен), яңадан һөнәри әзерлекнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациясен чагыштыруны гамәлгә ашыра (әгәр гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре белән мондый таләпләр каралган булса).

Министрлык конкурс комиссиясе эшчәнлеге өчен, шулай ук кандидатларның конкурс процедураларын үтүе өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудыра.»;

4.16 пунктның беренче абзацында «ләкин профессиональ һәм шәхси сыйфатлар» сүзләрен «ләкин профессиональ дәрәҗә, профессиональ һәм шәхси сыйфатлар» сүзләре белән алмаштырырга.

Министр вазыйфаларын башкаручы А.Г. Галимов